ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БӘЙРӘКӘ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

КАРАР №7

Бәйрәкә ав 07 февраль 2022 ел

Татарстан республикасы Ютазы муниципаль районы Бәйрәкә авыл җирлеге Советының 2021 елның 02 июлендәге «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Бәйрәкә авыл җирлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен раслау турында»гы 6 санлы карарына түбәндәге үзгәрешләр кертү турында

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 131-ФЗ санлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Бәйрәкә авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1.Татарстан республикасы Ютазы муниципаль районы Бәйрәкә авыл җирлеге Советының 2021 елның 02 июлендәге «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Бәйрәкә авыл җирлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен раслау турында»гы 6 санлы карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә.

1.1. 6.1 пунктта. түбәндәге әчтәлекле «К» пунктчасы өстәргә:

к) йорт территориясендә үсеп килүче яшел үсентеләрне тиешле хәлдә тоту, авария-куркыныч тудыручы һәм коры-сары ботакларны кисәргә, авария-куркынычтудыручы һәм коры-сары агачларны бетерергә.

1.2. 6.2 пунктта. "П» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

п) йорт янындагы территориядә клумбалар, чәчәк түтәлләре, декоратив коймалар һәм кече архитектура формалары буларак автомобиль покрышкалары куллану.

2. Әлеге карар махсус мәгълүмат стендларында рәсми халыкка игълан ителгән көннән, Ютазы муниципаль районының рәсми сайтында http://jutaza.tatarstan.ru веб-адрес буенча урнаштырылган көннән һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча кабул ителгән көннән үз көченә керә.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп тору Бәйрәкә авыл җирлеге башлыгына йөкләнә.

Бәйрәкә авыл жирлеге башлыгы А.О. Әхмәтшина